# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

## № 1

январь

1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
1999

# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№1*
*гыйнвар*
*1999*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
1999

Лицензия № 174 1996 елның 03.10 бирелде
Җитештерүгә тапшырылды
Формат А5. Тиражы 1150 нөсхә. Заказы 1579 от 18.02.99.
Бәясе килешү буенча.
"АБАК" нәшрияты.
420045 Казан, Н. Ершов ур., 31[б].
Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять АБАК-хөзмәт күрсәтү үзәгендә басылды
Лицензия № 0080 1997 елның 03.12 бирелде
420107 Казан, Һади Такташ ур., 105

*ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696*
**Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы
© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 1998

# Эчтәлек

## I

402."Хосусый детектив эшчәнлек һәм саклау эшчәнлеге турында" *Татарстан Республикасы Законы* ........ 5

403."Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" *Татарстан Республикасы Законы* ........ 20

404."Ак Барс" банкының устав капиталында дәүләт өлешен арттыруга ассигнованиеләрне раслау турында" *Татарстан Республикасы Законы* ........ 29

405."Мөлкәтнең сакланышын тәэмин итмәгән өчен административ җаваплылык турында" *Татарстан Республикасы Законы* ........ 30

406."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 гыйнварендагы утырышы көн тәртибе турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 31

407."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы - Корылтае депутатларына Мөрәҗәгате турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 32

408."Татарстан Республикасының кайбер район, шәһәр судлары судьяларын сайлау турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 33

409."Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 34

410."Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары вәкилләренең җыелышын үткәрү турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 35

## II

411."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясен чакыру турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 37

412."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе каравына кертелүче мәсьәләләр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 37

413."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы язгы сессиясен чакыру турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 38

414."1999 елның 20 гыйнварендა Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 38

415."1999 елның 20 гыйнварендა Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт

Советы карарлары проектлары турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 39
416."Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсенең Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының дәүләтара мөнәсәбәтләре үсешендә әһәмияте һәм роле" халыкара фәнни-гамәли конференциясен уздыру хакында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 40
417."Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау нәтиҗәләре турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 41
418."Татарстан Республикасының рәсми исемен бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау нәтиҗәләре хакында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 42
419."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1998 елның 21 һәм 22 декабрендәге XVII пленар сессиясендә Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 42

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАРҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 402. Хосусый детектив эшчәнлек һәм саклау эшчәнлеге турында

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә әлеге Законның максаты Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен шартнамә нигезендә түләүле һәрьяклы яклаудан гыйбарәт.

### 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. **Хосусый детектив эшчәнлек һәм саклау эшчәнлеге**

Әлеге Законда хосусый детектив эшчәнлек һәм саклау эшчәнлеге Татарстан Республикасы эчке эшләр органнарының махсус рөхсәте (лицензиясе) булган субъектлар тарафыннан физик һәм юридик затларга үз клиентларының законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатларында шартнамә нигезендә түләүле хезмәт күрсәтү буларак билгеләнә. Хосусый детектив эшчәнлек шөгыльләнүче гражданнарның закон белән дәүләт органнары компентенциясенә кертелгән оператив – эзләү гамәлләрен башкарырга хокуклары юк. Хокук саклау органнары хезмәткәрләренең хокукый статусын беркетүче законнар детектив эшчәнлекне һәм саклау эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнарга кагылмый.

2 статья. **Төп төшенчәләр**

Әлеге Законда түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

хосусый саклау эшчәнлеге – билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Татарстан Республикасы эчке эшләр органнары тарафыннан бирелгән тиешле лицензияләре булган юридик затларның үз клиентларының законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатларында шартнамә нигезендә түләүле саклау хезмәтләре күрсәтү ул;

хосусый детектив эшчәнлек – билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм эчке эшләр органнары тарафыннан бирелгән махсус лицензияләре булган юридик һәм (яисә) физик затларның үз клиентларының законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатларында шартнамә нигезендә түләүле детектив хезмәтләре күрсәтү ул;

хосусый саклау оешмасы – әлеге Законның 6 статьясында каралган саклау хезмәтләре күрсәтү өчен хуҗалык ширкәте яисә җәмгыяте рәвешендә гамәлгә куелучы оешма ул;

юридик затның иминлек хезмәте – юридик затның үз иминлеген тәэмин итү мәнфәгатьләрендә саклау-детектив хезмәтләре күрсәтү өчен төзелүче аерымланган бүлекчәсе ул;

хосусый сакчы – хосусый саклау эшчәнлегенә законда билгеләнгән тәртиптә лицензия алган һәм хосусый саклау оешмасында яисә юридик зат иминлеге хезмәтендә эшләүче зат ул;

хосусый детектив – хосусый детектив эшчәнлеккә законда билгеләнгән тәртиптә лицензия алган һәм хосусый детектив оешмада, юридик затның иминлеге хезмәтендә эшләүче яисә юридик зат барлыкка китермичә генә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче зат ул;

тән сакчысы – шартнамә нигезендә гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклаучы хосусый сакчы ул;

саклана торган объектлар – хокукка каршы гамәлләрдән якланырга тиешле биналар, төзелмәләр, корылмалар, транспорт чаралары, башка төрле мөлкәт, шулай ук территорияләр ул;

саклау гамәлләре – саклана торган объектларның һәм гражданнарның иминлеген тәэмин итү гамәлләре бергәлеге ул;

пропуск режимы – затларның һәм транспорт чараларының саклана торган объектка контрольсез үтеп керү, аннан чыгу, шулай ук аңа матди байлыкларны рөхсәтсез кертү, аннан алып чыгу, транспортта кертү һәм чыгару мөмкинлеген булдырмый калырлык гамәлләр һәм кагыйдәләр бергәлеге ул;

объект эчендәге режим – матди байлыкларның саклanышын тәэмин итүгә юнәлдерелгән эчке хезмәт тәртибенең һәм янгын куркынычсызлыгының куелган таләпләрен саклана торган объекттагы затлар тарафыннан үтәү тәртибен билгеләүче гамәлләр һәм кагыйдәләр бергәлеге ул.

**3 статья. Хосусый саклау эшчәнлеге һәм детектив эшчәнлек бурычлары**

Хосусый саклау эшчәнлегенең һәм детектив эшчәнлекнең бурычлары түбәндәгеләр була:

юридик һәм физик затларга законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатларында шартнамә нигезендә түләүле хезмәт күрсәтү;

гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, юридик һәм физик затларның милкенә карата хокукка каршы гамәлләр кылудан саклау;

саклана торган объектлар территориясендә пропуск режимын гамәлгә ашыру, хокук бозуларны кисәтү һәм булдырмый калу;

һәлакәтләр, афәтләр, янгыннар, табигый бәла-казалар вакытында һәм башка гадәттән тыш хәлләрдә кешеләрне коткару, аларга табибкә кадәр үк ярдәм күрсәтү, шулай ук караучысыз калган мөлкәтне саклау буенча кичектергесез гамәлләрдә катнашу.

**4 статья. Хосусый саклау эшчәнлегенең һәм детектив эшчәнлекнең принциплары**

Хосусый саклау эшчәнлеге һәм детектив эшчәнлек законлылык, гуманизм, кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен үтәү, яклау, хөрмәт итү принциплары нигезендә тормышка ашырыла.

**5 статья. Хосусый детектив эшчәнлекнең һәм саклау эшчәнлегенең хокукый нигезе**

Хосусый детектив эшчәнлекнең һәм саклау эшчәнлегенең хокукый нигезен Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка закон актлары тәшкил итә.

**6 статья. Хосусый саклау эшчәнлегенең һәм детектив эшчәнлекнең төрләре**

Татарстан Республикасы территориясендә җинаятьчеләрне эзләү хезмәтләренең әлеге Закон нигезендә түбәндәге төрләре рөхсәт ителә:

1) процесста катнашучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә граждани эшләр буенча белешмәләр җыю;

2) базарны өйрәнү, рәсми сөйләшүләр өчен мәгълүмат җыю, ышанычсыз рәсми партнерларны ачыклау;

3) фирма тамгаларын һәм исемнәрен эшкуарлык эшчәнлегендә хокукка каршы файдалану, намуссыз конкуренция, шулай ук коммерция серен тәшкил итүче мәгълүматларны фаш итү хәлләрен билгеләү;

4) аерым гражданнарның язма ризалыклары буенча алар белән хезмәт контрактлары яисә башка төрле контрактлар төзегәндә биографияләренә кагылышлы һәм шәхесне характерлый торган бүтән мәгълүматларны ачыклау;

5) хәбәрсез югалган гражданнарны эзләү;

6) гражданнарның яисә предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның югалган мөлкәтен, шул исәптән документларын да эзләү;

7) процесста катнашучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә җинаять эшләре буенча белешмәләр җыю. Шундый белешмәләр җыю турында клиент белән контракт төзегән мизгелдән бер тәүлек эчендә хосусый детектив алдан сорашып белүче затка, тикшерүчегә, прокурорга яки әлеге җинаять эшен алып баручы судка бу хакта язмача хәбәр итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы территориясендә саклау хезмәтләренең әлеге Закон нигезендә түбәндәге төрләрен күрсәтү рөхсәт ителә:

1) гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген яклау;

2) милекчеләрнең мөлкәтен, шул исәптән транспортировкала-ганда саклау;

3) саклана торган объектларда һәм территорияләрдә контроль-пропуск режимын тормышка ашыру;

4) түбәндәге эш төрләрен башкарырга лицензия булганда, янгыннан саклау сигнализациясе чараларын проектлаштыру, монтажлау һәм алардан файдаланганда хезмәт күрсәтү;

5) клиентларга хокукка каршы гамәл кылулардан хокукый яклау мәсьәләләре буенча консультация бирү һәм тәкъдимнәр әзерләү;

6) массакүләм гамәлләр үткәрелә торган урыннарда түләүсез яисә шартнамә нигезендә хокук тәртибен тәэмин итү;

7) мәгълүматларны яклау системаларын проектлаштыру, монтажлау һәм алардан файдаланганда хезмәт күрсәтү.

## 2 БҮЛЕК. ДЕТЕКТИВ ЭШЧӘНЛЕКНЕ ҺӘМ САКЛАУ ЭШЧӘНЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ОЕШМАЛАРНЫҢ ХОКУК САКЛАУ ОРГАННАРЫ БЕЛӘН ҮЗАРА МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

### 7 статья. **Детектив эшчәнлекне һәм саклау эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның хокук саклау органнары белән үзара мөнәсәбәтләре юнәлешләре**

Татарстан Республикасының хокук саклау органнары детектив эшчәнлекне һәм саклау эшчәнлеген башкаручы оешмаларга, тапшыру өчен санкцияләнгән мәгълүматларның исемлеген, аларны бирү тәртибен һәм алардан санкцияләнмәгән килеш файдаланган өчен җаваплылыкны билгеләп, түләүсез һәм түләүле мәгълүмати ярдәм һәм башка төрле ярдәмне оештыра алалар. Эчке эшләр органнары детектив эшчәнлекне һәм саклау эшчәнлеген башкаручы оешмаларга кирәк очракта алар эшчәнлек алып баручы районнарда җинаятьчелекнең торышын характерлаучы күзәтүләр, юнәлеш бирүче сводкалар, белешмәләр җибәрәләр.

Хокук саклау органнары табигый бәла-казалар, массакүләм чуалышлар, аеруча куркыныч җинаятьчеләрне эзләү белән бәйле гадәттән тыш хәлләрдә эш итүләр турындагы гамәлләрнең үрнәк планнарына детектив эшчәнлекне һәм саклау эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмаларның үзара хезмәттәшлеге мәсьәләләрен кертә алалар. Хокук саклау органнары хәбәрсез югалганнарны һәм яшеренүче җинаятьчеләрне эзләгәндә, аларның үзләре саклый торган объектларда һәм территорияләрдә күренү ихтималын исәпкә алып, хосусый детективларны һәм сакчыларны, аларның җитәкчеләре белән килешеп, җәлеп итәләр.

Детектив эшчәнлекне һәм саклау эшчәнлеген башкара торган оешмаларның финанс-хуҗалык эшенә, законнарда билгеләнгән нигезләрдән гайре, бернинди дә дәүләт органнары һәм башка төрле органнар катнаша алмыйлар.

### 8 статья. **Детектив эшчәнлекне һәм саклау эшчәнлеген башкаручы оешмаларның җәмәгатьчелек тәртибен саклауда катнашулары**

Мәдәни, спорт гамәлләре һәм башка төрле гамәлләр уздырганда, хосусый детектив эшчәнлекне һәм саклау эшчән-

леген башкаручы оешмаларга, хокук саклау органнары белән килешеп, хокук тәртибен саклауны тәэмин итүдә хокук саклау органнарына түләүсез йә түләүле ярдәм итү хокукы бирелә.

## 3 бүлек. Хосусый детектив эшчәнлек

### 9 статья. Хосусый детектив

Татарстан Республикасының 21 яшькә җиткән, хосусый детектив эшчәнлеккә законда билгеләнгән тәртиптә лицензия алган һәм әлеге Законның 6 статьясындагы беренче өлешендә каралган хезмәтләрне күрсәтүче гражданы хосусый детектив дип танылa. Детектив эшчәнлек хосусый детективның төп шөгыле булырга тиеш, аны дәүләт хезмәте йә иҗтимагый берләшмәләрдә сайланып куела торган түләүле эш белән бергә алып бару рөхсәт ителми.

### 10 статья. Хосусый детективларның гамәлләре

Детектив эшчәнлекне башкарганда, әлеге Законның 6 статьясындагы беренче өлешендә санап үтелгән хезмәтләрне күрсәтү максатларында, кирәкле мәгълүмат алу өчен гражданнардан һәм урындагы затлардан аларның ризалыгы белән телдән сорашу уздыру, белешмәләр юнәлтү, хуҗаларының ризалыгы белән аларның әйберләрен һәм документларын өйрәнү, корылмаларны, биналарны һәм башка объектларны тышкы яктан карап чыгу, күзәтү рөхсәт ителә. Хосусый детектив эшчәнлек барышында видео- һәм аудиоязмалар, кинога һәм фотога төшерүләр, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә зыян китермәслек техник һәм башка төрле чараларны, шулай ук оператив радио- һәм телефон элемтәләре чараларын куллану рөхсәт ителә.

Хосусый детективларларның үз гомерләренә һәм сәламәтлекләренә куркыныч янауга бәйле хезмәт күрсәтүләр кирәк булганда, махсус чаралар куллану рөхсәт ителә, аларның төрләре, аларны сатып алу, исәпкә алу, саклау һәм үзең белән йөртү тәртибен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели.

### 11 статья. Хосусый детектив эшчәнлеккә лицензия бирү

Татарстан Республикасы территориясендә юридик һәм физик затларга хосусый детектив эшчәнлеккә лицензияләр бирү аларның дәүләт теркәве урыны буенча эчке эшләрнең тиешле органы тарафыннан башкарыла.

Хосусый детектив булып эшләргә лицензия алуны дәгъвалаучы граждан тиешле эчке эшләр органына түбәндәге документларны шәхсән үзе тапшырырга тиеш:

– анкета;

– фотографияләр;

– сәламәтлек турында медицина белешмәсе;

– гражданлыгын раслаучы документлар;

– юридик белеме булуын яки хосусый детектив булып эшләү өчен махсус әзерлек үткәнлеген йә тикшерү яисә оператив бүлекчәләрдә кимендә өч ел эш стажы барлыгын раслаучы документлар;

– махсус чаралар, элемтә чаралары һәм башка төрле техник чаралар кирәклеге һәм аларны кулланырга ниятләве турындагы белешмәләр;

– әгәр хезмәт итүе утлы коралларны куллануга бәйле булса, хәрбиләштерелгән дәүләт оешмаларында хезмәт итүен раслаучы документлар.

Эчке эшләр органнары лицензия бирү турындагы карар чыгару өчен тапшырылган кирәкле документларда бәян ителгән белешмәләрнең дөреслеген тикшерергә хаклы, шул исәптән лицензия алырга дәгъвалаучы граждан белән әңгәмә үткәрү юлы белән дә.

Лицензия түбәндәгеләргә бирелми:

21 яшькә җитмәгән гражданнарга;

сәламәтлек саклау органнарында психик авыру, алкоголизм һәм наркоманлык буенча исәптә торучы гражданнарга;

алдан исәпләп кылынган җинаять өчен хөкем ителгән гражданнарга;

җинаять кылуда гаепләнүче гражданнарга, аларның гаеплелеге турындагы мәсьәләне законда билгеләнгән тәртиптә хәл иткәнчегә кадәр;

яман аты чыгу аркасында дәүләт хезмәтеннән, суд органнарыннан, прокуратура органнарыннан һәм башка хокук саклау органнарыннан эштән җибәрелгән гражданнарга;

хокук саклау органнарының хосусый детектив эшчәнлекне һәм саклау эшчәнлеген тикшереп торучы элеккеге хезмәткәрләренә, әгәр аларның эштән азат ителүләренә бер ел үтмәгән булса.

Хосусый детектив булып эшләү өчен лицензия аны алырга дәгъвалаучы гражданның гариза биргән көненнән бер

ай эчендә Татарстан Республикасы эчке эшләр органы тарафыннан өч елга бирелә һәм ул индивидуаль хосусый детектив оешманы гамәлгә кую урыны буенча шәһәр (район) администрациясендә аны дәүләт теркәвенә алу өчен яисә хосусый детективлар оешмасы белән хезмәт шартнамәсе (контракты) төзү өчен нигез була. Лицензияләр биргән өчен җыемнар түләү тәртибе һәм күләме Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Лицензия бирүдән баш тарткан очракта, гариза җибәргән гражданга, эчке эшләр органы, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш. Бу карарга яисә гаризаны карау вакытын бозуга карата эчке эшләрнең югарырак органына яки судка шикаять белдерелергә мөмкин. Хосусый детектив булып эшләү өчен лицензия алган гражданга тиешле эчке эшләр органы тарафыннан бер үк вакытта аның шәхесен таныклаучы мәгълүм үрнәктәге документ бирелә.

### 12 статья. **Хосусый детектив эшчәнлеге өлкәсендә чикләүләр**

Хосусый детективларга түбәндәгеләр тыела:

1) әзерләнә торган яисә кылынган җинаятьләр турында мәгълүм булган фактларны хокук саклау органнарыннан яшереп калу;

2) үзен хокук саклау органнары хезмәткәре итеп күрсәтү;

3) урындагы тиешле затларның яисә хосусый затларның язма ризалыгыннан башка хезмәт биналарында яки башка төрле биналарда видео– һәм аудиоязмалар, фотога һәм кинога төшерү;

4)гражданнарның хокукларына һәм ирегенә зыян салырлык гамәлләр кылу;

5) гражданнарның гомерен, сәламәтлеген, намусын, абруен һәм мөлкәтен куркыныч астына куярлык гамәлләр кылу;

6) материалларны фальсификацияләү яисә клиентны ялгыш юлга кертү;

7) җыелган мәгълүматны фаш итү, аны клиентының мәнфәгатьләренә каршы яисә өченче зат мәнфәгатьләрендә куллану;

8) үз лицензиясен башка затларга файдаланырга биреп тору;

9) аерым затларның шәхси тормышына, сәяси һәм дини инануларына бәйле белешмәләр җыю;

10) хокук саклау органнары, дәүләт хакимияте һәм ида-

рәсе органнары хезмәткәрләренә карата аларның шәхси тормышына бәйле белешмәләр, шулай ук граждан һәм җинаять эшләренә бәйле белешмәләр җыю.

Хосусый детективның хат язышуларның, телефоннан сөйләшүләрнең, телеграф хәбәрләренең һәм башка төр хәбәрләрнең яшеренлеген ачуга йә яки шәхеснең кагылгысызлык гарантиясен бозуга бәйле гамәлләре өчен законда билгеләнгән җаваплылык карала.

**13 статья. Хосусый детектив оешма белән клиент арасында шартнамә**

Хосусый детектив оешма үзенең һәр клиенты белән хезмәт күрсәтү турында язма шартнамә төзергә тиеш, анда килешүче яклар турында белешмәләр бирелергә, шул исәптән лицензиянең номеры һәм ул бирелгән дата, йөкләмәнең эчтәлеге, аны үтәү вакыты, акчалата чыгымнарның һәм хезмәт күрсәтүләр өчен гонорарның якынча суммасы, һәр якның җаваплылык дәрәҗәсе, шартнамәне төзү датасы күрсәтелергә тиеш.

Яклар арасында конфиденциаль нигездә шартнамәнең барлык пунктлары буенча килешүгә ирешелсә һәм ул әлеге статьяның беренче өлешендә билгеләнгән барлык шартларны үтәп тутырылган булса, шартнамә төзелгән дип санала.

Шартнамәдә хосусый детектив оешманың үз клиентына башкарылган эш нәтиҗәләре турында язма хисабын биреп бару карала, ул хисапта клиентны кызыксындырган төп сорауларга шартнамә нигезендә җаваплар булырга тиеш. Хосусый детектив оешманың гонорары һәм чыгымнары турында төгәл исәп-хисап хисапка кушылып бирелә. Хисапның күчермәсе предприятие архивында өч ел дәвамында сакланырга тиеш.

Хосусый детектив оешма һәм аның хезмәтләреннән файдаланучы клиент арасында төзелгән шартнамәдә билгеләнгән хезмәт күрсәтүләр өчен исәп-хисаплар буенча һәм башка нигезләрдәге бәхәсләр суд тәртибендә карала.

**14 статья. Хосусый детектив эшчәнлеккә лицензияләрнең гамәлдә булу вакытын озайту һәм аны юкка чыгару**

Хосусый детективлар һәм хосусый детектив оешмалар лицензиянең гамәлдә булуын вакытында озайтырга, шулай ук лицензияне биргән органның норматив-хокукый актлары белән

билгеләнгән хосусый детектив эшчәнлек турындагы нигезләмәләрнең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләрне шул органның таләбе буенча аңа бирергә тиешләр. Лицензия аның гамәлдә булу вакыты чыгарга бер ай кала мөрәҗәгать итүченең үтенечнамәсе буенча 5 елга озайтыла.

Лицензия биргән орган аны түбәндәге очракларда юкка чыгарырга хокуклы:

– хосусый детектив (хосусый детектив оешма) әлеге Законда каралган таләпләрне, шулай ук Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының аларның эшчәнлегенең хокукый нигезен тәшкил итүче башка законнары нигезләмәләрен һәм башка төрле норматив-хокукый актларын бозганда йә үтәмәгәндә;

– лицензия бирү өчен нигез булган тапшырылган документларда ялган мәгълүматлар табылганда;

– хокукка каршы детектив хезмәтләре күрсәткәндә;

– юридик зат яки иминлек хезмәте бетерелгәндә;

– лицензияне башка юридик затка тапшырганда;

– лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында вакытында мөрәҗәгать итмичә, ул гамәлдән чыгарылса;

– хосусый детективка карата гаепләү карары закон көченә кергәндә;

– лицензиядән ихтыярый баш тартканда.

Хосусый детективка карата гаепләү карары чыгарылган очраклардан гайре, лицензияне юкка чыгару турындагы карарны эчке эшләр органы лицензия хуҗасын алдан язмача кисәткәннән соң гына кабул итә. Кисәтүдә кайсы хокукый нормаларның һәм кагыйдәләрнең бозылуы яки тиешенчә үтәлмәве күрсәтелә, шулай ук ясалган хокук бозуларны төзәтү өчен вакыт билгеләнә.

Ихтыярый баш тарткан очраклардан гайре, лицензияне юкка чыгарганда, аны юкка чыгарган көннән башлап өч ел үткәннән соң аны алу өчен кабат мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Лицензияне юкка чыгаруның законлылыгы суд тарафыннан билгеләнгән очракта, суд карары чыгарылган көннән башлап өч ел үткәннән соң аны алу өчен кабат мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

15 статья. **Лицензиянең гамәли чикләре**

Лицензия Татарстан Республикасы чикләрендә, аерымланган административ район йә шәһәр чикләрендә хосусый

детектив йә саклау эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гариза бирелгән көннән соң бер ел эчендә Татарстан Республикасының эчке эшләр органы тарафыннан өч елга бирелә. Лицензияләр биргән өчен җыемнар алу тәртибе һәм күләмнәре Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

## 4 бүлек. Хосусый саклау эшчәнлеге

### 16 статья. **Саклау өлкәсендә хезмәт күрсәтүләр**

Саклау өлкәсендә әлеге Законның 6 статьясындагы 2 өлешендә санап кителгән хезмәтләрне күрсәтү, бары тик аларны башкару өчен махсус гамәлгә куелган оешмаларга гына, рөхсәт ителә.

Оешмаларның саклау эшчәнлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең карарлары нигезендә дәүләт саклавында булырга тиешле объектларга кагылмый. Саклау оешмаларына төрле милек рәвешләрендәге, шул исәптән дәүләт милкендәге мөлкәтләрне коралланып сакларга, шулай ук гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерми торган техник һәм башка төрле чаралардан, оператив радио һәм телефон элемтәсе чараларыннан файдаланырга рөхсәт ителә. Хосусый саклау оешмалары җитәкчеләре, шулай ук әлеге оешмаларның шушы Законның 6 статьясындагы 2 өлешендә санап кителгән хезмәтләрне күрсәтүче хезмәткәрләре (алга таба – сакчылар) хосусый детектив эшчәнлек өчен билгеләнгән тәртиптә лицензия алырга тиешләр, моның өчен әлеге Законның 11 статьясында (җиденче абзацыннан гайре), күрсәтелгән документларны бирергә тиешләр, болардан тыш, ул затлар сакчы булып эшләү өчен махсус әзерлек узуларын раслый торган йә эчке эшләр органнарында яисә иминлек органнарында кимендә өч ел эш стажы булуын раслый торган документлар бирәләр.

Сакчылар хосусый саклау предприятиесенең формасын киеп, эш урыны буенча теркәлү номеры куелган һәм саклау оешмасының исеме язылган күкрәк тамгасы тагып йөрергә тиешләр. Форманың үрнәге Татарстан Республикасы эчке эшләр органнары белән килештерелергә тиеш.

Саклау оешмалары җитәкчеләренә, шулай ук ул оешмаларның хезмәткәрләренә саклау эшчәнлеге белән бер үк вакытта дәүләт хезмәтендә эшләү йә иҗтимагый берләш-

мәләрдә сайланып куела торган түләүле эштә эшләү рөхсәт ителми.

Хосусый саклау эшчәнлегенә әлеге Законның 12 статьясында билгеләнгән чикләүләр кагыла.

**17 статья. Хосусый саклау оешмаларына, шулай ук юридик затларның иминлек хезмәтләренә лицензия бирү**

Хосусый саклау оешмаларына, шулай ук юридик затларның иминлек хезмәтләренә эшчәнлек алып бару өчен лицензияләр бирү аларның дәүләт теркәве урыны буенча тиешле эчке эшләр органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Юридик затның җитәкчесе лицензия алу өчен эчке эшләр органына түбәндәгеләрне тапшыра:

1) оешманың тулы исеме һәм оештыру—хокукый рәвеше, аның юридик адресы, банк исеме һәм исәп-хисап счетының номеры күрсәтелгән гариза;

2) дәүләт теркәве турындагы таныклыкның һәм гамәлгә кую документларының нотариуста таныкланган күчермәсе;

3) салым инспекциясендә исәпкә куелу турында белешмә;

4) эшчәнлек юнәлешләре турында, персоналның фаразланган саны, корал һәм махсус чараларга, техник яисә башка төрле чараларга ихтыяҗлар турында белешмәләр күрсәтелгән аңлатма язуы;

5) билгеләнгән лицензия җыемын түләү турында квитанция.

Юридик затның иминлек хезмәтен теркәү өчен иминлек хезмәте уставы һәм иминлек хезмәте уставын килештерү мөмкинлеге турында эчке эшләр органы бәяләмәсе өстәмә рәвештә тапшырыла.

Дәүләтнең хәрбиләштерелгән оешмаларында кимендә өч ел хезмәт иткән, хезмәтләре сакчылар әзерләү буенча уку йортларында укымыйча утлы корал куллануга бәйле булган һәм уңай сәбәпләр нигезендә хезмәттән азат ителгән офицерларга лицензия бирү рөхсәт ителә.

Хосусый саклау оешмасы җитәкчесенең югары белемле булуы мәҗбүри.

Лицензия бирүдән баш тарткан очракта эчке эшләр органы, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә язмача хәбәр итәргә тиеш. Бу карарга яисә гаризаны карау вакытын бозуга карата югарырак эчке эшләр органына

яисә судка шикаять белдерергә мөмкин.

Хосусый саклау оешмалары тарафыннан стажер итеп алынучы гражданнар лицензияләнергә тиеш түгел. Стажировка чоры 6 айдан да артык була алмый.

18 статья. **Хосусый сакчының хокуклары**

Хосусый сакчы саклана торган объектның иминлеген тәэмин итү максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

1)саклана торган объектның иминлеген тәэмин итүгә бәйле рәвештә гражданнардан үзенең законлы күрсәтмәләрен үтәүләрен таләп итәргә;

2)саклана торган объектларда шартнамәдә каралган очракларда гражданнарның документларын тикшерергә, әйберләрен, транспорт чараларын карап чыгарга;

3)хокук бозучыларга карата законда билгеләнгән тәртиптә хезмәт коралы, махсус чаралар кулланырга;

4)саклана торган объектларга, шулай ук саклаучы затларга карата хокукка каршы гамәлкылган затларны хокук бозган урында тоткарларга һәм кичекмәстән эчке эшләр органнарына тапшырырга.

Хосусый сакчының гражданнарның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозуы законда билгеләнгән җаваплылыкка китерә. Сакчыларга җинаятьчеләрне эзләү ысулларын куллану тыела.

## 5 бүлек. Юридик затның иминлек хезмәте

19 статья. **Юридик затның иминлек хезмәте**

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмалар, милек рәвешләренә карамастан, юридик затның шәхси иминлеген тәэмин итү ихтыяҗларында детектив-саклау хезмәте күрсәтү, агымдагы һәм исәп-хисап счетларын ачу хокукы белән, юридик затның аерым бүлекчәләрен (алга таба – иминлек хезмәте) гамәлгә куя алалар. Иминлек хезмәте җитәкчесе һәм персоналы әлеге Закон нигезләмәләре нигезендә лицензия алырга тиеш. Лицензия бирүдән, аның гамәлдә булу вакытын озайтудан баш тарту, лицензияне юкка чыгару һәм эчке эшләр органнарының карарларына шикаять белдерү хосусый детектив эшчәнлек өчен әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә башкарыла. Иминлек хезмәте үз предприятиесенең иминлеген тәэмин итүгә бәйле булмаган

хезмәтләр күрсәтмәскә тиеш.

## 6 бүлек. Саклау-детектив ассоциацияләре төзү

20 статья. **Катнаш детектив-саклау эшчәнлеге**

Хосусый саклау оешмаларына һәм хосусый детективлар оешмаларына детектив-саклау эшчәнлеген тормышка ашыру өчен, үзләренең мөстәкыйльлеген һәм юридик зат хокукларын саклаган хәлдә, шартнамә нигезендә ассоциацияләр төзергә рөхсәт ителә.

21 статья. **Хосусый детектив-саклау оешмалары ассоциацияләренең норматив-хокукый актлар әзерләүдә катнашулары**

Үз эшчәнлекләрен җайга салу өчен, үзләренең юридик һәм мөлкәти һәм башка төрле хокукларын яклау өчен ихтыярый нигездә төзелгән хосусый детектив-саклау оешмалары ассоциацияләре хосусый сакчыларның һәм хосусый детективларның мәнфәгатьләренә кагылучы Татарстан Республикасы закон проектларын һәм Татарстан Республикасының башка норматив актларын әзерләүдә катнашалар.

## 7 бүлек. Хосусый детектив эшчәнлекне һәм саклау эшчәнлеген башкарганда махсус чаралар һәм утлы корал куллану

22 статья. **Махсус чараларны куллану кагыйдәләре**

Хосусый детективлар һәм сакчылар эчке эшләр органнары өчен билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә махсус чаралар кулланырга хокуклы.

Хосусый детективлар һәм сакчылар түбәндәге очракларда махсус чаралар кулланырга хокуклы:

1)үзләренең гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч яный торган һөҗүмгә каршы тору өчен;

2)үзләре саклый торган милеккә карата җинаять кылуны булдырмаска тырышканда хокук бозучы физик каршылык күрсәтсә.

Хосусый детективның, сакчының гомеренә һәм сәламәтлегенә яисә саклана торган мөлкәтнең иминлегенә куркыныч янарлык итеп кораллы каршылык күрсәтелү, төркем-төркем яки башкача һөҗүм итү очракларыннан тыш, йөклелеге сизелеп торган хатыннарга, инвалидлык билгеләре ачыктан-ачык күренеп торган затларга һәм балигъ булмаганнарга карата

масхус чаралар куллану тыела.

23 статья. **Утлы корал куллану кагыйдәләре**

Сакчы түбәндәге очракларда утлы корал кулланырга хокуклы:

1) аның гомеренә турыдан-туры куркыныч янаганда, һөҗүмне кире кагу өчен;

2) саклана торган милеккә кораллы яки төркем-төркем һөҗүм итүне кире кагу өчен;

3) корал кулланырга ниятләве турында (һавага атып) кисәтү өчен, шулай ук тревога сигналы яки ярдәм сорап сигнал бирү өчен.

Әгәр кораллы каршылык күрсәтмәсәләр, сакчының гомеренә яки ул саклый торган милекнең иминлегенә куркыныч янарлык итеп, кораллы яки төркем-төркем һөҗүм итү очракларыннан тыш, хатын-кызларга, инвалидлык билгеләре ачыктан-ачык күренеп торган затларга, ничә яшьтә булулары күренеп торган яисә сакчыга билгеле булган балигъ булмаганнарга карата, шулай ук халык күпләп җыелып торган урында утлы корал куллану аркасында чит затларга зыян килерлек булганда, утлы корал куллану тыела.

Утлы корал кулланган һәр очрак турында сакчы корал куллану урыны буенча эчке эшләр органына кичекмәстән хәбәр итәргә тиеш.

## 8 бүлек. Хосусый детектив эшчәнлекне һәм саклау эшчәнлеген тикшереп һәм күзәтеп тору

24 статья. **Хосусый детектив эшчәнлекне һәм саклау эшчәнлеген тикшереп һәм күзәтеп тору**

Татарстан Республикасы территориясендә хосусый детектив эшчәнлекне һәм саклау эшчәнлеген тикшереп торуны Татарстан Республикасы эчке эшләр министрлыгы башкара.

Хосусый детектив һәм саклау оешмалары, иминлек хезмәтләре эшчәнлеген тикшереп торырга вәкаләтле урындагы затлар алардан үз компетенциясе чикләрендә тиешле документлар бирүләрен таләп итәргә һәм тикшерү вазыйфаларын башкару өчен кирәкле мәгълүматларны телдән яки язма рәвештә алырга хокуклы.

Әлеге Законның үтәлешен Татарстан Республикасы Прокуратурасы күзәтеп тора.

## 9 бүлек. Законсыз рәвештә детектив һәм саклау оешмалары төзегән өчен җаваплылык

25 статья. **Законсыз рәвештә детектив һәм саклау оешмалары төзегән өчен җаваплылык**

Әлеге Законда каралмаган детектив һәм саклау оешмаларын, иминлек хезмәтләрен төзү яки аларның эшчәнлеге әлеге Закон нигезендә җаваплылыкка китерә.

26 статья. **Әлеге Законны гамәлгә кертү**

Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1998 елның 25 ноябре
№ 1873

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 403. "Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

1 статья. "Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды турында" 1992 елның 22 декабрендәге Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992 ел, № 11-12), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

## "Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды турында Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды (алга таба Югары арбитраж суд) Татарстан Республикасы Конституциясенең 152 статьясы нигезендә юридик затлар белән, юридик зат барлыкка китермичә генә эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче гражданнар арасындагы граждан, административ һәм башка хокукый мөнәсәбәтләрдән килеп чыгучы икътисадый бәхәсләрне хәл иткәндә закон билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасында гадел хөкемне башкаручы иң

югары суд органы булып тора.

2 статья. **Югары арбитраж суд турында законнар**

Югары арбитраж суд эшчәнлеген оештыру, эшчәнлек тәртибе һәм аның компетенциясе әлеге Закон белән, шулай ук "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләрне чикләү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының 1994 елның 15 февралендәге шартнамәсе нигезендә Россия Федерациясенең арбитраж процессуаль законнары белән билгеләнә.

3 статья. **Югары арбитраж судның бурычлары**

Үз карамагындагы бәхәсләрне хәл иткәндә Югары арбитраж судның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

юридик затларның һәм гражданнарның эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлеге өлкәсендә бозылган яисә дәгъваланучы хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;

эшкуарлык һәм башка төрле икътисадый эшчәнлек өлкәсендә законлылыкны ныгытуга һәм хокук бозуларны кисәтүгә ярдәм итү.

4 статья. **Югары арбитраж суд эшчәнлегенең төп принциплары**

Югары арбитраж суд эшчәнлеге законлылык принциплары, судьяларның бәйсезлеге, алыштыргысызлыгы һәм кагылгысызлыгы, аларның бары тик законга буйсынуы, оешмаларның һәм гражданнарның закон һәм суд алдында тигезлеге, якларның ярышуы һәм эшләрне карауның хәбәрдарлыгы нигезендә корыла.

5 статья. **Югары арбитраж суд кабул иткән суд актларының мәҗбүрилеге**

Югары арбитраж судның закон көченә кергән суд актлары – карарлары, билгеләмәләре, карарлары барлык дәүләт органнары,җирле үзидарә органнары, башка төрле органнар, оешмалар, урындагы затлар һәм гражданнар өчен мәҗбүри була.

6 статья. **Югары арбитраж судның закон чыгару инициативасы хокукы**

Югары арбитраж суд Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Сове-

тында закон чыгару инициативасы хокукына ия.

7 статья. **Югары арбитраж судны сайлау**

Югары арбитраж суд судьяларның сайлап куелуы башлангычларында төзелә.

Югары арбитраж судның шәхси составы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайлана.

Югары арбитраж суды Рәисе урынбасарлары һәм судьялары урыннарына кандидатларны сайлап алу Югары арбитраж судның квалификация коллегиясе бәяләмәсе нигезендә Югары арбитраж суд Рәисе тарафыннан башкарыла.

Судьялар урынына кандидатларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына чыгарганчы, алар Татарстан Республикасы Дәүләт Советының тиешле даими комиссияләре утырышларында алдан карала.

25 яшькә җиткән, югары юридик белеме, юридик белгечлек буенча кимендә биш ел эш стажы булган, үзенә тап төшерерлек гамәлләр кылмаган, квалификация имтиханын биргән һәм судьяларның квалификация коллегиясе тәкъдимен алган Татарстан Республикасы гражданы Югары арбитраж суд судьясы итеп сайлана ала.

Югары арбитраж суд судьясының вәкаләтләре чоры чикләнми.

Югары арбитраж суд судьясының вәкаләтләре бары тик Югары арбитраж судның квалификация коллегиясе карары буенча гына туктатылырга мөмкин.

8 статья. **Югары арбитраж судның составы**

Югары арбитраж суд түбәндәге составта эшли:

Югары арбитраж судның Пленумы;

Югары арбитраж судның Президиумы;

граждан һәм башка хокукый мөнәсәбәтләрдән килеп чыгучы бәхәсләрне карау буенча суд коллегиясе;

административ хокук мөнәсәбәтләреннән килеп чыгучы бәхәсләрне карау буенча суд коллегиясе.

9 статья. **Югары арбитраж судның вәкаләтләре**

Югары арбитраж суд:

Россия Федерациясе Югары арбитраж суды компетенциясенә кертелгән эшләрдән гайре, Россия Федерациясендә арбитраж судлар карамагындагы барлык эшләрне беренче

инстанциядә карый;

шушы судта беренче инстанциядә каралган эшләрне апелляцион инстанциядә кабат карый;

үзе элек кабул иткән һәм закон көченә кергән суд актларын яңа ачылган сәбәпләр буенча яңадан карый;

үзе теләсә-кайсы инстанциядә карый торган эштә кулланылган яисә кулланылырга тиешле Татарстан Республикасы законының һәм башка төрле норматив актның конституциячеллеген тикшерү турындагы үтенече белән Татарстан Республикасының Конституция судына һәм Россия Федерациясенең Конституция судына мөрәҗәгать итә;

суд гамәлиятен өйрәнә һәм гомумиләштерә;

законнарны һәм башка норматив-хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

суд статистикасын анализлый.

10 статья. **Югары арбитраж суды Пленумы**

Югары арбитраж суд эшчәнлегенең иң мөһим мәсьәләләрен карау өчен Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Пленумы төзелә.

Югары арбитраж суд Пленумы:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә тәкъдимнәр кертү мәсьәләсен хәл итә;

Татарстан Республикасы законнарының, башка норматив-хокукый актларының конституциячеллеген тикшерү турындагы үтенечләр белән Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хакындагы мәсьәләләрне хәл итә;

Югары арбитраж суд Рәисе тәкъдиме буенча Югары арбитраж суд судьялары арасыннан Пленум секретарен сайлый;

Югары арбитраж суд Рәисе тәкъдиме буенча Югары арбитраж суд Президиумына керүче судьяларны раслый;

суд гамәлияте мәсьәләләрен карый.

Югары арбитраж суд Пленумы Югары арбитраж суд Рәисе, аның урынбасарлары һәм Югары арбитраж суд судьялары составында эшли.

Югары арбитраж суд Пленумы Югары арбитраж суд Рәисе тарафыннан кирәк булган саен чакырыла.

Югары арбитраж суд Пленумы утырышларында Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе, Татарстан Республикасы Прокуроры, Татарстан Республикасы юстиция министры, шулай

ук Югары арбитраж суд Рәисе чакыруы буенча башка затлар да катнашырга мөмкин.

Югары арбитраж суд Пленумы, составының кимендә өчтән икесе катнашканда, мәсьәләләрне хәл итү хокукына ия була.

Югары арбитраж суд Пленумы карарлары ачык тавыш биреп, Пленумда катнашучы әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителәләр.

Югары арбитраж суд Пленумы карарларына Югары арбитраж суд Рәисе һәм Пленум секретаре имза сала.

11 статья. **Югары арбитраж суд Президиумы**

Югары арбитраж суд Президиумы Югары арбитраж суд Рәисе, аның урынбасарлары, суд составлары рәисләре составында эшли. Югары арбитраж суд Пленумы карары белән аның составына Югары арбитраж суд судьялары да кертелергә мөмкин.

Югары арбитраж суд Президиумы Югары арбитраж суд Рәисе тарафыннан кирәк булган саен чакырыла.

Югары арбитраж суд Президиумы, әгъзаларының күпчелеге катнашканда, мәсьәләләрне хәл итү хокукына ия була.

Югары арбитраж суд Президиумы карарлары ачык тавыш биреп, Президиумда катнашучы әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителәләр, һәм Югары арбитраж суд Рәисе аларга имза сала. Президиум әгъзалары тавыш бирүдән тыелып калырга тиеш түгел.

Югары арбитраж суды Президиумы:

Югары арбитраж суд Рәисе тәкъдиме буенча Югары арбитраж судның суд коллегияләре әгъзаларын һәм суд составларының рәисләрен раслый;

суд гамәлияте мәсьәләләрен карый;

Югары арбитраж суд эшен оештыруның, фәкать югары арбитраж суды Пленумы компетенциясенә карамаган, башка мәсьәләләрен карый.

12 статья. **Югары арбитраж судның суд коллегияләре**

Югары арбитраж судта граждан һәм башка төрле хокукый мөнәсәбәтләрдән килеп чыгучы бәхәсләрне карау коллегиясе һәм административ-хокукый мөнәсәбәтләрдән килеп чыгучы бәхәсләрне карау коллегиясе эшли, аларның составы Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Рәисе тәкъдиме буенча

судьялар арасыннан Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды Президиумы тарафыннан раслана.

Суд коллегияләренә рәисләр – Югары арбитраж суд Рәисе урынбасарлары җитәкчелек итә.

Югары арбитраж суд Рәисе кирәк чакта эшләрне карау өчен үз күрсәтмәсе буенча бер суд коллегиясе судьяларын икенче суд коллегиясе составына җәлеп итәргә хокуклы.

Суд коллегияләре Югары арбитраж суд карамагындагы барлык эшләрне беренче һәм апелляция инстанцияләрендә карый, суд гамәлиятен өйрәнә һәм гомумиләштерә, законнарны һәм башка норматив-хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, суд статистикасын анализлый.

13 статья. **Югары арбитраж судның суд составы**

Югары арбитраж судта тиешле суд коллегиясенә керүче судьялардан суд составлары төзелә.

Суд составларын Югары арбитраж суд Рәисе төзи.

Суд составына Югары арбитраж суд Президиумы тарафыннан раслanучы рәис җитәкчелек итә.

14 статья. **Югары арбитраж суд Рәисе**

Югары арбитраж судка Рәис җитәкчелек итә.

Югары арбитраж суд Рәисе судья булып тора һәм Россия Федерациясе Арбитраж процессуаль кодексында билгеләнгән процессуаль вәкаләтләрне башкара.

Югары арбитраж суд Рәисе:

Югары арбитраж судның һәм аның аппаратының эшчәнлеген оештыра;

закон белән үзенә бирелгән вәкаләтләр чикләрендә урынбасарларының бурычларын бүлә һәм аларның вазыйфаларын билгели;

Югары арбитраж суд судьялары арасыннан суд составлары төзи, шулай ук Югары арбитраж суд аппаратының структур бүлекчәләрен оештыра;

Югары арбитраж суд аппаратына гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра, суд аппараты хезмәткәрләрен эш урыннарына билгели һәм вазыйфаларыннан азат итә;

Югары арбитраж суд Пленумын һәм Президиумын чакыра һәм аларның утырышларында рәислек итә;

дәүләт, җәмәгать органнары һәм башка органнар, урындагы затлар һәм гражданнар белән мөнәсәбәтләрдә Югары

арбитраж суд исеменнән эш итә;

үзенә закон белән бирелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Югары арбитраж суд Рәисе Югары арбитраж суд утырышларында, шул исәптән Югары арбитраж суд коллегияләре утырышларында рәислек итәргә хокуклы.

Югары арбитраж суд Рәисе боерыклар һәм күрсәтмәләр чыгара.

Югары арбитраж суд Рәисе Югары арбитраж суд исеменнән Татарстан Республикасы законнарының һәм норматив актларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвен тикшерү турында һәм аларның конституциячел булмавын тану хакында Татарстан Республикасы Конституция судына тәкъдимнәр кертә.

Югары арбитраж суд Рәисе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты утырышларында, шулай ук аларның президиумнары утырышларында катнашырга хокуклы.

15 статья. **Югары арбитраж суд Рәисенең беренче урынбасары, урынбасарлары**

Югары арбитраж суд Рәисенең беренче урынбасары, урынбасарлары судьялар булып торалар һәм Россия Федерациясе Арбитраж процессуаль кодексында билгеләнгән процессуаль вәкаләтләрне башкаралар. Алар Югары арбитраж суд утырышларында, шул исәптән аның коллегияләре утырышларында рәислек итәргә хокуклы.

Югары арбитраж суд Рәисенең беренче урынбасары, урынбасарлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, шулай ук аларның президиумнары утырышларында катнашырга хокуклы.

Югары арбитраж суд Рәисенең беренче урынбасары, урынбасарлары вазыйфалар бүлешү нигезендә суд коллегияләренә җитәкчелек итә, суд аппаратының структур бүлекчәләре эшчәнлеген оештыра.

Югары арбитраж суд Рәисе булмаган очракта, аның вәкаләтләрен – Рәиснең беренче урынбасары, ә беренче урынбасары да булмаганда, Рәис урынбасарларының берсе башкара.

16 статья. **Югары арбитраж суд аппараты**

Югары арбитраж судның эшчәнлеге Татарстан Респуб-

ликасы Югары арбитраж суды аппараты тарафыннан тәэмин ителә.

Югары арбитраж суд аппараты:

эштә катнашучы затларны судка кадәр алдан кабул итүне оештыра;

документлар кабул итә һәм бирә, Югары арбитраж суд документларының күчермәләрен раслый, документлар җибәрүне һәм тапшыруны башкара, Югары арбитраж судның депозит исәбенә кертелергә тиешле дәүләт пошлиналарының, суд чыгымнарының түләнүен, шулай ук арбитраж штрафларының түләнүен тикшерә;

эшләрне суд утырышларында карауга әзерләү буенча судьяларга ярдәм итә:

эшләрнең барышын һәм аларның судта узу вакытларын исәпкә алып бара, эшләрне һәм документларны саклауны гамәлгә ашыра;

хөкем гамәлиятен өйрәнә һәм гомумиләштерә;

законнарны һәм башка норматив-хокукый актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, мәгълүмати-белешмә эшләре алып бара;

арбитраж суд эшчәнлеге өлкәсендә статистика исәбен алып бара.

Югары арбитраж суд аппараты хезмәткәрләре Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтендә булалар.

Югары арбитраж суд аппараты хезмәткәрләренең хокуклары, бурычлары, җаваплылыгы һәм аларның дәүләт хезмәтен узу шартлары закон белән билгеләнә.

17 статья. **Югары арбитраж суд эшчәнлеген финанслау һәм оештыру-техник яктан тәэмин итү**

Югары арбитраж судны финанслау суд эшчәнлеген законнар нигезендә тулы һәм бәйсез башкару мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Татарстан Республикасының республика бюджеты проектының Татарстан Республикасы Югары арбитраж судын финанслау өлешен Югары арбитраж суд Рәисе белән берлектә эшли. Фикер каршылыклары булганда, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасының республика бюджеты проектына, үз бәяләмәсе белән бергә, Татарстан Республикасы Югары арбитраж судының тәкъдимнәрен өстәп бирә.

Югары арбитраж суд Рәисе һәм аның урынбасарлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Татарстан Республикасының республика бюджеты буенча фикер алышуларда катнашырга хокуклы.

Югары арбитраж судны финанслау Татарстан Республикасының республика бюджетында аерым юл белән карала.

Югары арбитраж судны матди-техник тәэмин итү һәм хезмәт бинальары белән, шул исәптән Югары арбитраж судның һәр судьясын киңәшләшү өчен аерым бүлмәләр һәм суд утырышлары заллары белән тәэмин итү, шулай ук аның хезмәткәрләренә шифаханәдә-курортта дәвалану, медицина, торак һәм социаль-көнкүреш хезмәте күрсәтү Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

18 статья. **Югары арбитраж судның санлы составы, структурасы, штат расписаниесе**

Югары арбитраж суд судьяларының һәм аның аппараты хезмәткәрләренең гомуми саны Югары арбитраж суд рәисе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә.

Югары арбитраж судның структурасы һәм штат расписаниесе Югары арбитраж суд Рәисе тарафыннан раслана.

19 статья. **Статистик исәпкә алу**

Югары арбитраж суд билгеләнгән тәртиптә статистик исәпкә алуны алып бара һәм үз эшчәнлеге турындагы статистик белешмәләргә анализ ясый.

20 статья. **Югары арбитраж судның суд хакимияте символлары һәм аның хокукый хәле**

Югары арбитраж суд бинасына Татарстан Республикасының Дәүләт флагы урнаштырыла, ә суд утырышлары залларында шулай ук Татарстан Республикасының Дәүләт флагы һәм Татарстан Республикасының Дәүләт гербы куела.

Югары арбитраж суд юридик зат була. Югары арбитраж судның Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте төшерелгән, татар һәм рус телләрендә үз исеме язылган мөһере була.

Югары арбитраж суд судьяларына таныклыклар Татарстан

Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан бирелә.

21 статья. **Югары арбитраж судның эшләү урыны**

Югары арбитраж судның даими эшләү урыны – Татарстан Республикасының башкаласы – Казан шәһәре.

22 статья. **Югары арбитраж судның даими төбәк сессияләре**

Татарстан Республикасының зур шәһәрләрендә һәм район үзәкләрендә Югары арбитраж суд Президиумы карары белән беренче инстанциядәге арбитраж эшләрне карау өчен Югары арбитраж судның даими төбәк сессияләре төзелергә мөмкин".

2 статья. "Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законын басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасының тиешле закон актларын кабул иткәнгә кадәр Югары арбитраж суд судьяларының хокукый хәле һәм статусы, аларның эшчәнлеге гарантияләре, судьяларга квалификация класслары һәм суд аппараты хезмәткәрләренә классны чиннар бирү тәртибе, Татарстан Республикасы Югары арбитраж суды судьяларына һәм хезмәткәрләренә хезмәт хакын билгеләү тәртибе һәм күләме Россия Федерациясе законнарындагыча була, дип билгеләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1998 елның 22 декабре
№ 1926

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 404. "Ак Барс" банкының устав капиталында дәүләт өлешен арттыруга ассигнованиеләрне раслау турында

1 статья. "Ак Барс" Акционер коммерция банкы устав капиталында дәүләт (Татарстан Республикасы) өлешен арттыруга Татарстан Республикасының республика бюджетыннан 1550 млн. сум күләмендә ассигнованиеләрне расларга.

2 статья. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарына, Татарстан Республикасының республика бюдже-

тында берләшкән максатчан бюджет фондларына, дәүләт (республика) предприятиеләренә, учреждениеләренә һәм оешмаларына "Ак Барс" Акционерлар коммерция банкында катнашучылар булырга рөхсәт итәргә.

3 статья. Әлеге Закон матбугатта басылган көненнән гамәлгә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1998 елның 22 декабре
№ 1928

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 405. Мөлкәтнең сакланышын тәэмин итмәгән өчен административ җаваплылык турында

Әлеге Закон, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар мөлкәтенең сакланышын тәэмин итү өлкәсендә милекне яклауга һәм хокук бозуларны кисәтүгә юнәлдерелгән.

1 статья. Татарстан Республикасында объектларның техник ныгытылу һәм сигнализация белән җиһазлану кагыйдәләрен бозуларны бетерү турында эчке эшләр органнарының күрсәтмәләрен үтәмәгән өчен –

предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләренә хезмәт өчен түләүнең 5 минималь күләменә кадәр штраф салына.

Мөлкәтне урлау шарты булырлык шундый ук гамәлләр өчен –

предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләренә хезмәт өчен түләүнең 10 минималь күләменә кадәр штраф салына.

Искәрмә. 1 статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән объектлар дигәндә наркотик матдәләр, корал, сугыш кирәк-яраклары тупланган биналар, корылмалар һәм законнар белән махсус саклау режимы билгеләнгән башка объектлар күз алдында тотыла.

2 статья. Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр эчке эшләр органнарының шуңа вәкаләтле урындагы затлары тарафыннан төзелә һәм биш көн эчендә судка җибәрелә.

3 статья. Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта район (шәһәр) суды (судьясы) тарафыннан каралалар.

4 статья. Әлеге Законда каралган хокук бозулар өчен штрафлар түбәндәгеләргә җибәрелә дип билгеләргә: 75 проценты – административ материалларны карау урыны буенча шәһәр, район бюджетларына, 25 проценты – Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Ведомстводан тыш саклау идарәсенең махсус счетына.

5 статья. Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

6 статья. "Дәүләт милкендәге һәм коммуналь милектәге мөлкәтнең, акчаларның һәм кыйммәтле кәгазьләрнең саклanышы өлкәсендәге хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 5); "Дәүләт милкендәге һәм коммуналь милектәге мөлкәтнең, акчаларның һәм кыйммәтле кәгазьләрнең саклanышы өлкәсендәге хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында" Татарстан Республикасы Югары Советы карары (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 5) үз көчен югалткан дип танырга.

**Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев**

Казан шәһәре,
1998 елның 25 декабре
№ 1941

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 406. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 гыйнварендагы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 гыйнварындагы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасының кайбер район, шәһәр судлары судьяларын сайлау турында.

2. "Умартачылык турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

3. "Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

4. "Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

5. "Башкортостан Республикасы халыкларының телләре турында" Башкортостан Республикасы законы проекты эшләнү белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышына мөрәҗәгате хакында.

6. "Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары вәкилләренең җыелышын үткәрү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

7. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 гыйнвары
№1966

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 407. Татарстан Республикасының кайбер район, шәһәр судлары судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Судьялар итеп сайларга:

Казан шәһәренең Вахитов район судына
Гафаров Роман Фәһим улын;

Татарстан Республикасының Югары Ослан район судына
Тюфтина Ольга Михайловнаны;

Татарстан Республикасының Зәй шәһәр судына
Мингалимова Рәмзия Равил кызын;

Казан шәһәренең Киров район судына
Мелентьева Резидә Роберт кызын,
Низамов Эмиль Рафаэль улын;

Татарстан Республикасының Түбән Кама шәһәр судына
Әхмәтҗанова Розалия Ислам кызын;

Казан шәһәренең Яңа Савин район судына
Ганиев Эмиль Мәсхүт улын.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 гыйнвары
№1968

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 408. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы - Корылтае депутатларына Мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы - Корылтае депутатларына Мөрәҗә-гате текстын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Мөрәҗәгатьне массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 гыйнвары
№ 1967

## Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы - Корылтае депутатларына МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле коллегалар, дуслар!

Сезнең “Башкортостан Республикасы халыкларының телләре турында” закон проектын татар теленең статусын исәпкә алмыйча беренче укылышта кабул итүегез Татарстан Республикасы халкында киң иҗтимагый яңгыраш китереп чыгарды.

Халыкларыбызның күп гасырлык дуслык традицияләре буенча һәм тугандаш республикаларыбыз арасында хезмәттәшлек турында шартнамә нигезендә Татарстан Республикасының закон чыгару һәм башкарма хакимият органнары Башкортостан Республикасының социаль-икътисадый, мәдәни үсешкә һәм үз дәүләтчелеген ныгытуга юнәлеш тотуын хуплый.

Без, Татарстан Республикасы халык депутатлары, Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы - Корылтае һәм Татарстан Респуб-ликасы Дәүләт Советы кабул итә торган карарлар нәтиҗәсендә тугандаш халыкларыбыз арасындагы үзара мөнәсәбәтләрдә киеренкелек тудырмау яклы.

Хөрмәтле Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы - Корылтае халык депутатлары! “Башкортостан Республикасы халыкларының телләре турында” Башкортостан Республикасы Законында Башкортостан Республикасы халыкларының шактый өлешен тәшкил итүче татар халкы теленең дәүләт статусы билгеләнер, дигән ышаныч белдерәбез.

Казан шәһәре,
1999 елның 20 гыйнвары

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 409. “Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. “Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында” Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән тәкъдимнәр һәм

искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләрне 1999 елның 20 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенә җибәрергә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясе, кертелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, әлеге Закон проектын 1999 елның 20 мартына кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 гыйнвары
№ 1969

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 410. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары вәкилләренең җыелышын үткәрү турында

Республикада җирле үзидарәне тагын да үстерүне тәэмин итү һәм “Җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. 1999 елның 26 февралендә Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары вәкилләренең җыелышын үткәрергә:

Җыелышны әзерләүне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына йөкләргә.

2. Татарстан Республикасы халык депутатлары җирле Советларына 1999 елның 3 февраленә кадәр җирле үзидарәләр башлыкларының (рәисләренең) Татарстан Республикасы җирле үзидарә вәкилләре җыелышына делегатлар сайлау буенча җыелышларын үткәрүне тәэмин итәргә, вәкиллек нормалары түбәндәгечә: җирле үзидарәләрнең ике Советыннан (комитетыннан) бер вәкил.

3. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары

вәкилләре җыелышларында катнашу өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте әгъзаларын, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының җаваплы хезмәткәрләрен, халык депутатларының җирле Советлары рәисләрен, рәис урынбасарларын, җәмәгать оешмалары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен чакырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары З.Р.Вәлиевага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 гыйнвары
№ 1970

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 411. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясен чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясен Казан шәһәрендә 1999 елның 12 февралендә чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 13 гыйнваре
№ 1943

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 412. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче пленар сессиясе каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**

1. Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы турында.
2. “Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында” Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсенә имза салынуга биш ел тулу хакында.
3. “Татарстан Республикасы каршында аерым уңышлары булган гражданнарны өстәмә матди тәэмин итү турында”

Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

4. “Татарстан Республикасы Конституциясенең 89,111 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

5. “Иминлек турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

6. Татарстан Республикасы Югары суды судьяларын сайлау турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 13 гыйнваре
№ 1944

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 413. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы язгы сессиясен чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының парламентта даими нигездә эшләүче Татарстан Республикасы халык депутатлары составындагы язгы сессиясен Казан шәһәрендә 1999 елның 20 гыйнваренда чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 13 гыйнваре
№ 1945

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 414. 1999 елның 20 гыйнваренда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның 20 гыйнварендa Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1.Татарстан Республикасының кайбер район, шәһәр судлары судьяларын сайлау турында.

2.“Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

3.“Умартачылык турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

4. “Этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы проекты турында.

5. “Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 13 гыйнваре
№ 1946

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 415. 1999 елның 20 гыйнварендa Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

1999 елның 20 гыйнварендa Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектларын кертергә:

1.“Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне

дәвам итү хакында.

2. Татарстан Республикасының кайбер район, шәһәр судлары судьяларын сайлау турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 13 гыйнваре
№ 1947

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 416. "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсенең Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының дәүләтара мөнәсәбәтләре үсешендә әһәмияте һәм роле" халыкара фәнни-гамәли конференциясен уздыру хакында

"Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсенә имза салынуга биш ел тулуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

1.1999 елның 10 февралендә Казан шәһәрендә"Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Шартнамәсенең Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының дәүләтара мөнәсәбәтләре үсешендә әһәмияте һәм роле" халыкара фәнни-гамәли конференциясен уздырырга.

2. Халыкара фәнни-гамәли конференцияне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә (исемлек кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 13 гыйнваре
№ 1950

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 417. "Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау нәтиҗәләре турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе карарын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе бәяләмәсен исәпкә алып, "Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләп бетерү өчен кире кайтарырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 13 гыйнваре
№ 1957

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 418. "Татарстан Республикасының рәсми исемен бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проектын алдан карау нәтиҗәләре хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе карарын һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы бәяләмәсен исәпкә алып, "Татарстан Республикасының рәсми исемен бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проектын кире кагарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 13 гыйнваре
№ 1958

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 419. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1998 елның 21 һәм 22 декабрендәге XVII пленар сессиясендә Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1998 елның 21 һәм 22 декабрендәге XVII пленар сессиясендә Татарстан Республикасы халык депутатлары тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты адресына әйтелгән тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каравына җибәрергә (кушымта итеп бирелә).

Тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре турында, бер айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы халык депутатларына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына хәбәр итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре В.Н.Липужинага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 13 гыйнваре
№ 1959

Искәрмәләр өчен